# Чыгарылыш кичәсе

***Җыр “Әссәлә мөгәләйкем” – дуэт.***

**Егет.** Яңа тормыш килгән шәһәребезгә,
Яңа төрдә гимназия ачылган,
Шушы елдан алып, безнең көнгә,
12 еллап гомер салынган.

**Кыз.** Шул гомердә бик күп мөгәллимнәр
Шактый еллар эшләп киткәннәр.
Аң – белем биргәннәр балаларга,
Халкыбызга ярдәм иткәннәр.

**Егет.** Яңа төзелгән шәһәр гимназиясенә
Бик күп яшь кадрлар килгәннәр,
Иңгә төшкән барлык авырлыкны
Бергә эшләп, бергә җиңгәннәр.

**Кыз.** Мәктәбебез тарихы бик озын,
Борылып – борылып аккан сулар кебек.
Һәр борылышта берәр бабаң торган,
Әкият геройлары шулар кебек.

**Егет.** Дәрес бара, укытучы сөйли,
Күпме бала сорау яудыра.
Нәни дуслар кайбер дәресләрдә
Шаулашып та ала үзара.
Укытучы, эшең җиңел түгел,
Мәшәкатьле синең язмышың.
Сабырлыгын җыеп яшь буынның
Төзәтәсең күпме ялгышын.

**Кыз.** Уртаклашыр өчен кайгысын да,
Шатлыгын да вакыт табасың.
Салкыннарда җылы сүзең белән
Йөрәкләргә учак ягасың.
Аяз дөнья, кешелек бәхете өчен
Көрәшергә безне өндәдең,
“Яратыгыз җирне!” – дидең һаман.
“Мине яратыгыз!” – димәдең.

***(Музыка)***

**Укытучы:** - Хөрмәтле балалар, хөрмәтле ата-аналар һәм кунаклар. Менә бүген безнен башлангыч мәктәп белән саубулашу көнебез дә килеп җитте. Дүрт ел элек

сез 1 нче сыйныфка килгән идегез. Шушы еллар эчендә авыр белем баскычына күтәрелдегез: укырга, язарга, төрле – төрле мисаллар чишәргә өйрәндегез.

Бүген безгә моңсу да, күңелле дә. Күңелле, чөнки башлангыч мәктәпне уңышлы тәмамлау көнен бәйрәм итәбез. Моңсу, чөнки бер-беребез белән аерылышабыз. Анда сезне тагын да авыррак, кызыграк, мавыктыргыч сынаулар көтә.

**Алып баручы:** Кадерле укучылар! Әле кайчан гына сез мәктәпкә барырга әзерләнеп йөри идегез. Гимназист костюмнарын ничә тапкыр киеп карадыгыз. “1 нче сентябрь кайчан җитә”, - дип, әниләрегезне аптыратып бетердегез. Мәктәптә сезне укытучы апагыз каршы алды, җитәкләп Белем иленә алып керде. Шул көннәрнең ничек узуын хәтергә төшерик әле.

***Плакатлар:***

***Татар гимназиясе. “Белем илендә сәяхәт әкиятен тәкъдим итә”.***

***Рольләрдә: 4 нче сыйныфның матур – матур кызлары һәм малайлары.***

**1 нче сыйныф.**

**1 нче сентябрь – 2003 нче ел.**

**Әкият сөйләүче әби:** Борын – борын заманда ямьле Бәләбәй шәһәрендә яшәгәннәр ди матур апалар һәм абыйлар. Булган ди аларның матур кызлары һәм малайлары. Көннәрдән бер көнне алар шушы шәһәрнең иң төзек, иң яңа мәктәбенә белем алырга килгәннәр.

**Музыка.** Кулга – кул тотышып чәчәкләр тотып балалар керә.

***Җыр “Белем бәйрәме”.***

Чәчәкләр тотып кулга,
Без чыктык матур юлга.
Һәркем белә, әлбәттә,
Без барабыз мәктәпкә.

Безне котлыйлар әтиләр:
- Дәү үстегез, - диләр.
Өйрәтәләр әниләр:
- Әйбәт булыгыз, - диләр.
Дәү әти, дәү әниләр:
- Хәерле юл, хуш, - диләр.

Бүгенгедәй күз алдында тора
Очар коштай йөргән чакларын
Сумка тотып белем алырга дип,
Борма сукмак буйлап атлавым.

Дәфтәрләр, китаплар барлыйсың
Яңа көч, яңа дәрт йөрәктә.
Син инде уйнарга бармыйсың, -
Кыңгырау чакыра мәктәпкә.

***Кыңгырау шалтырый.***

Башланып китте укулар,
“А” дигән хәреф белән.
~~Әти - әниләр~~ дә безнең
Башланган әнә шуннан.
1 нче сентябрьдән башлап безгә кем ярдәм итте?

**Бергә:** Әлифба!

Әлифба, әлифба

Беренче битеңне

Ачкан көн хәтердә

Зур бәйрәм шикелле.

**Әкият сөйләүче:** Укучыларны баштагы мәлдә ручкалары, каләмнәре һич тә тыңламады. Тик тылсымлы белем ачкычы ***(күрсәтә)*** һәм аларның тырышлыгы бу кыенлыкны җиңәргә ярдәм итте.

Ния инде хәрефләр

Басырга теләмиләр.

Минем тырышуымны

Һич кенә аңламыйлар.

**Тактага матур итеп, “Без бәхетле балалар” дип яза.**

**Җыр – “Саумы кояш”.**

**Әкият сөйләүче:** Шулай итеп безнең укучылар уку баскычларыннан атлый башладылар. Һәм көннәрдән бер көнне хат алдылар:

Хөрмәтле балалар!

Сез бик олы бормалы юлга чыккансыз. Үзегезгә юлдаш итеп сабырлыкны, тырышлыкны алсагыз, сезне зур табыш көтәчәк! – дип балалар хатны укыдылар да нинди табыш микән ул ди уйлый башладылар. Ләкин хаттагы сүзләрне онытмыйча тырышлык белән эшкә керештеләр. Көн артыннан көн үттә ай артыннан ай. Шулай итеп тырыша – тырыша безнең укучылар ел азагына килеп тә җиттеләр һәм соңгы көнне тагын бер хат алдылар:

Укучылар!

Сез ел буена армый – талмый эшләдегез, укыдыгыз һәм бөтенегез дә табыш эзләдегез. Таптыгызмы соң? Нәрсә булды соң инде ул?

**Барысы бергә:** Белем!

***2 нче сыйныф*** – *"Фән парады"*

*Җыр – "Күбәләкле болында".*

***Туган тел.***

Җыр булырлык сүзләр биргән
Матур телем, Туган телем
Рәхмәт сиңа күңел түрем.
"Туган тел", - иң әйбәт шигырь,
"Туган тел", - иң әйбәт җыр,
"Туган тел", - иң әйбәт китап,
"Туган тел", - иң әйбәт тел.
Туган тел әйбәт булганга, шигырьне дә, җырны да иң әйбәтедер.

**"Математика"**

Математика бик шәп, кызыклы бит ул.
Ул дәрестә өйрәндек без санарга,
Мәсәләләр чишәргә.
Мисаллар авыр гына
Түземлек кирәк монда
Утырасың баш ватып
Чишү юлларын табып.

**"Табигать белеме"**

Табигатьнең серләрен
Аяз, моңсу көннәрен,
Яңгырларын, карларын,
Урманнарын, кырларын,
Җәнлекләрен, кошларын,
Елгаларын, күлләрен

Барысын да белдерде
Табигатьне өйрәнү.

**“Җыр”**
Ул безнең күңел ачкычы
Килеп керә дәрескә
Монда юк “2” алучы
Юк укучы “өчлегә”
Яңа җырлар өйрәтә,
Уйната да, биетә,
Үзе уйный, үзе җырлый,
Безнең Әльфия Мукарамовна.

**“Хезмәт”**
Матур кулъяулыклар чиктек
Әниләргә бүләккә,
Уенчыклар да ясадык
Яраткан дәрес – хезмәттә.

**“Физкультура”**
Сикерәбез, йөгерәбез
Чаңгыда узышабыз
Төрле уеннар уйныйбыз
Тауда чана шуабыз.
Авыртса да елашмыйбыз
Көчсез күренмәс өчен
Бөтенебез дә яраттык
Физкультура дәресен.

**“Рәсем”**
Нәфис чәчәкләрен ясадык
Төрле буяулар белән.
Рәсем күңелле үтә шул
Әгәр төшерә белсәң.
Туган якның гүзәллеген
Тойсаң һәм якын күрсәң.

***Музыка уйный балалар чыгып китәләр.***

**Әкият сөйләүче.** Белем иле буйлап сәяхәт бик күңелле булды, чөнки укучылар уку белән беррәттән җырларга, биергә, күңел ачырга өйрәнделәр.

**3 нче сыйныф “Без күңел ачабыз”**
Әйдә, әйдә катырак бас
Биегәнне күрсеннәр
Баскан җирдә ут чыгарга
Безнең кызлар дисеннәр.

Эх, шома басабыз,
Биеп, күңел ачабыз.

*(Парные “Вальс”)*

**Әкият сөйләүче:**

Җырлыйк әле, җырлыйк әле
Җырлап ачыла күңел.
Җырлап ачылмаган күңел,
Мәңге ачылачак түгел.

***Концерт номерлары.***

***Җыр.***

**Әкият сөйләүче:**

Уйна әле, уйна әле,
Балкып китсен дөнья, гөрләсен.
Сыкрамасын йөрәк, сызламасын,
Сызламасын янсын дөрләсен.

***Концерт номерлары.***

**4 нче сыйныф. Сау бул, башлангыч мәктәп!**

***Җыр уйный. Балалар чәчәкләр белән керәләр***

**1)** Мин зур инде хәзер
4 нчене бетердем.
Бишенчегә барамын
Җәйне генә үткәрсәм.

**2)** Кечкенә булу кызык та
Вакыт тормый бит көтеп
Кайчан гына бала идек
Үсеп тә җиттек хәзер.

**3)** Зурайганбыз икән шул
Партага булмый сыеп
Аптырагач, аякларны
Куябыз аркылы сузып.

**4)** Булай булгач, дусларым
Кирәк нидер кылырга
Гел генә башлангычта

Ярышмени калырга?

**5)** Кәм дә кем күчәм ди
Бишенчегә барам ди
Шулар кулын күтәреп
Ризалыгын бирәм, ди.

**Бергә кул күтәреп:** Бергәләшеп, гөрләшеп, бишенчегә барабыз.

**6)** Туктагыз әле, тукта
Ә *(укытучының Исем Отчествасы)*
Каламени берүзе?

**7)** Сезсез бергә бигерәк
Күңелсез булып инде
Төрле – төрле апага
Төрле – төрле абыйга
Ничек күнербез инде

**Бергә:** Рәхмәт сезгә, беренче укытучыларыбыз.
***Җыр. Сез иң гүзәл кеше икәнсез!***

**8)** Киләсе ел бишенчедә
Укырбыз тагын да яхшырак.

**9)** Алда көтә әллә күпме
Мавыктыргыч күп эшләр.

**10)** Алда көтә зур юллар,
Төрле кызыклы фәннәр!
Белем дөньясына илтер
Мәктәптә үтәр көннәр.

**11)** Сау бул, 4 нче сыйныф
Башы син олы юлның
Һәрчак хәтерләрбез сине
Мизгеле дип балачакның.

**12)** Саумы 5 нче сыйныф
Ал безне кабул итеп
Хәзер инде без зурлар
Нинди шатлык, зур бәхет.

***Укытучыларга чәчәкләр бирәләр.***

**Әкият сөйләүче:** Әкиятебез ахырына якынлаша. Озын сүзнең кыскасы. Белем иле патшасы башлангыч мәктәпне тәмамлау көненә указ чыгарды. Игътибар!